| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**<br>ул. Советская, д.80,<br>с. Новошешминск,423190 | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**<br>Совет урамы, 80,<br>Яңа Чишмә авылы, 423190 |

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «25» гыйнварыннан № 24

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр прейскурантын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле һәм керем китерә торган башка хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2023 елның 29 декабрендәге 40-325 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымтада бирелгән «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр прейскурантын расларга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарлары үз көчләрен югалткан дип санарга:

2017 елның 31 маеннан 255 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәклəштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан керем китерә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәне раслау хакында»;

2023 елның 24 апрелennән 114 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәклəштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан керем китерә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәне раслау хакында».

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның «25» гыйнварындагы
24 номерлы карары белән
расланган

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү прейскуранты

| № т/б | Хезмәтнең атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе |
|---|---|---|
| 1 | Дискотека | 30 сум - район мәдәният йорты<br>20 сум - авыл мәдәният йорты, авыл клубы |
| 2 | Бильярд уены (сәгать) | 50 сум - район мәдәният йорты<br>30 сум - авыл мәдәният йорты, авыл клубы |
| 3 | Концертлар, спектакльләр, театральләштерелгән тамашалар, фестивальләр | 100 сум |
| 4 | Социаль - иҗади заказлар буенча түләүле хезмәтләр күрсәтү | 1500 сум |
| 5 | Сәхнә костюмнарын, реквизитларын прокатка алу | Тәүлегенә 500 сум |
| 6 | Озын буйлы курчаклар белән анимация хезмәтләре (1 шт x 1000 сум, 15 минут) | 1000 сум |
| 7 | Озын буйлы курчаклар прокаты | Көненә 500 см |
| 8 | 1 җырга фонограмма яздыру | 700 сум |
| 9 | Музыка уен кораллары прокатка | Сәгатенә 300 сум |
| 10 | Репертуар-методик материаллар сату | 150 сум |
| 11 | Коммерцияле булмаган оешмаларның уртак чараларында өлешләп катнашу | Тулай җыемның 13% ы |
| 12 | Шоу-программа, уен программалары, спорт-сәламәтләндерү хезмәтләре | 50 сум |
| 13 | Күргәзмәләр, һөнәрчелек продукциясе | Сәгатенә 500 сум |
| 14 | Күчермә – күбәйтү үзәге эше | 5 сум |
| 15 | Кинофильмнар прокаты | 50 сум - олылар билеты |

| | | |
|---|---|---|
| | | 30 сум - балалар билеты<br>20 сум - мәктәпкәчә яшьтәге балалар |
| 16 | Урам экранында реклама урнаштыру | Рәсем рәвешендәге текстлы белдерү (товарлар, хезмәтләр, эш) физик зат өчен тәүлегенә 250 сум, юридик затка - тәүлегенә 500 сум |
| | | Видео – афиша<br>(видео – белдерү)<br>Физик затлар өчен:<br>- 30 секундка кадәр – тәүлегенә 450 сум<br>- 1 минутка кадәр – тәүлегенә 750 сум<br>- 1,5 минутка кадәр – тәүлегенә 1000 сум<br><br>Юридик затлар өчен:<br>- 30 секундка кадәр – тәүлегенә 650 сум<br>- 1 минутка кадәр – тәүлегенә 950 сум<br>- 1,5 минутка кадәр – тәүлегенә 1300 сум |
| | | Бәйрәмнәргә видеороликлар (туган көн, юбилей)<br>Видео:<br>- 30 секундка кадәр – тәүлегенә 1500 сум<br>- 1 минутка кадәр – тәүлегенә 1800 сум<br>- 1,5 минутка кадәр – тәүлегенә 2100 сум |
| | | Фото:<br>- 30 секундка кадәр (10 фотога кадәр) – тәүлегенә 650 сум<br>1 минутка кадәр (20 фото) – тәүлегенә 950 сум<br>1,5 минутка кадәр (25 фото) – тәүлегенә 1300 сум |